КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 март г.Казань № 149

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен билгеләү турында» 2014 ел, 20 июнь, 429 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен билгеләү турында» 2014 ел, 20 июнь, 429 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Болгар» шәһәрлеге – Болгар дәүләте башкаласы» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимында:

егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәдәни мирас объектларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихый һәм мәдәни ядкарьләренә) мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру кагыйдәләрен, бу

мәгълүмати язмалар һәм билгеләрнең эчтәлеген, шулай ук урнаштыруны гамәлгә ашыру өчен нигез булган мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру һәм аларның эчтәлеге проектлары составына карата таләпләрне раслау турында» 2019 елның 10 сентябрендәге 1178 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру».»;

егерме дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин